РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ МАМАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӘМӘШИР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422104, с.Мамашир , ул Молодежная , д.29 Б Тел./факс: (884364) 36-6-04 e-mail:Mam.kuk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«1» апрель, 2026 ел Мәмәшир № 12

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Мәмәшир авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш урында Татарстан Республикасы чигенә туры китерү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы, «Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2025 елның 7 ноябрендәге 20 номерлы карары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Мәмәшир авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге халкының фикерен белдереп, Мәмәшир авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Мәмәшир авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш урында Татарстан Республикасы чигенә туры китерү белән килешергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында https://kukmor.tatarstan.ru,Мәмәшир авыл җирлегенең җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2025 елның 12 декабрендәге 8 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы: Әхмәтҗанов И.Г.